ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 май, 2019 ел № 31/7

Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 209-ФЗ санлы Федераль закон, 2018 елның 03 июлендәге «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 185-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2007 елның 04 октябрендәге 25/5 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында Нигезнамәгә(Шәһәр Советының 2009 елның 22 октябрендәге 43/9, 2010 елның 26 маендагы 50/8, 2011 елның 15 декабрендәге 15/9, 2012 елның 20 апрелендәге 18/8, 2015 елның 15 апрелендәге 39/11, 2018 елның 21 февралендәге 23/10, 2018 елның 08 ноябрендәге 27/11 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 19 бүлек исемендә «(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш)» сүзләренә алыштырырга;

2) 98 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «98. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының ярдәмче инфраструктурасын хасил итүче оешмаларга, шул исәптән җир участокларына (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек,

бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир участокларыннан тыш) бирү өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) муниципаль милек исемлеген (алга таба – Исемлек) формалаштыру, раслау, алып бару, рәсми бастыру, үзгәрешләр кертү Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3) 99 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1) муниципаль милек өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш);»

4) түбәндәге эчтәлектәге 109 нчы пунктны өстәргә: «109. Исемлеккә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирелгән җир кишәрлекләреннән тыш, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 маддәсендәге 1-10, 13-15, 18 һәм 19 пунктчаларында каралган җир кишәрлекләре кертелми.».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев